ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕТИГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
УРТА ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2023 Урта Тигәнәле ав. № 4

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча Координация советын төзү турында**

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү, кече һәм урта бизнесны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә социаль-икътисадый бурычларны хәл итүгә җәлеп итү максатларында «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча Координация советын төзү тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча Координация советын (алга таба-Совет) төзергә һәм аның составын расларга (2 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Алек-сеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча Координация советы турында Нигезләмәне расларга (3 нче кушымта).
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.К.Хәмәтвәлиев**

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Республикасы Алексеевск
муниципаль районының Урта Тигәнәле
авыл җирлеге башкарма комитетының
15.05.2023 ел, № 4
карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча Координация советын төзү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча Координация советы (алга таба-Совет) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән төзелә, үзгәртеп корыла һәм бетерелә.

2. Совет турындагы нигезләмә һәм аның шәхси составы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән раслана.

3. Советны Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы җитәкли, ул аның эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә.

4. Совет составына Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге башкарма комитеты вазыйфаи затлары, Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы депутатлары, бизнес-берләшмә, иҗтимагый һәм башка оешма вәкилләре керә.

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районының Урта Тигәнәле
авыл җирлеге башкарма комитетының
15.05.2023 ел, №4
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыркул авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча Координация советы составы

| | | |
|---|---|---|
| Хәмәтвәлиев И.К. | - | Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе |
| Муликова Г.Г. | - | Урта Тигәнәле авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре |
| | | Координацион совет әгъзалары: |
| Камалова З.М. | - | депутат (килештерү буенча) |
| Сафин Ф.М | - | Урта Тигәнәле авыл мәдәният йорты директоры (килештерү буенча) |
| Арсланова Н.А. | - | Түбән Тигәнәле авыл мәдәният йорты директоры (килештерү буенча) |

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районының Урта Тигәнәле
авыл җирлеге башкарма комитетының
15.05.2023 ел, № 4
карарына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча Координация советы турында нигезләмә

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча Координация советы (алга таба - Совет дип атала)-кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү, кече һәм урта бизнесны Урта Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә социаль-икътисади бурычларны хәл итүгә җәлеп итү максатларында төзелгән даими эшләүче киңәшмә органы.

2. Совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары, Татарстан Республикасының закон чыгару һәм норматив-хокукый актлары, Алексеевск муниципаль районының, Урта Тигәнәле авыл җирлегенең норматив-хокукый актлары һәм әлеге Нигезләмә нигезендә эш итә.

3. Совет түбәндәге максатлар өчен төзелә:

1) Урта Тигәнәле авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль сәясәтне эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга җәлеп итү;

2) Урта Тигәнәле авыл җирлеге өчен әһәмиятле һәм кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән инициативаларны тәкъдим итү һәм аларга ярдәм итү;

3) Урта Тигәнәле авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүне көйләүче норматив-хокукый актлары проектларына җәмәгать экспертизасы үткәрү;

4) Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә өстенлекләрне билгеләгәндә Урта Тигәнәле авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр эшләү;

5) Урта Тигәнәле авыл җирлеге гражданнарын, иҗтимагый берләшмәләрен һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен гражданнарның эшмәкәрлек эшчәнлегенә хокукларын гамәлгә ашыру һәм әлеге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләү мәсьәләләрен тикшерүгә җәлеп итү.

## II. СОВЕТ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

4. Совет үз максатлары нигезендә:

1) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының дәүләт хакимиятенең федераль органнарының территориаль органнары, Урта Тигәнәле авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеген оештыра, шулай ук кече һәм урта

эшмәкәрлек субъектларын, аларның берләшмәләрен, берлекләрен һәм ассоциацияләрен, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыра торган башка коммерциягә карамаган оешмаларны кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыруда катнашуга җәлеп итә;

2) Урта Тигәнәле авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлары проектларын эшләүдә катнаша һәм иҗтимагый экспертиза үткәрә;

3) кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемаларын анализлый һәм Урта Тигәнәле авыл җирлегенең норматив-хокукый актларын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшли;

4) Алексеевск муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү программасын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтүгә документларны карый һәм аны күрсәтү турында яки аннан баш тарту турында тәкъдимнәр чыгара;

5) Алексеевск муниципаль районы башкарма хакимияте органнары белән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәт ярдәме күрсәтү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә;

6) Урта Тигәнәле авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чараларының нәтиҗәлелеген анализлый;

7) Урта Тигәнәле авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлекнең уңай имиджын формалаштыруга ярдәм итә.

## III. СОВЕТ СОСТАВЫ

5. Совет составы Урта Тигәнәле авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан формалаштырыла һәм Кыркул авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән раслана.

6. Советны Совет Рәисе җитәкли, ә ул булмаганда Совет рәисе урынбасары.

7. Совет әгъзалары булып торалалар:

1) Урта Тигәнәле авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мәнфәгатьләрен белдерүче иҗтимагый берләшмәләр, кече һәм урта эшмәкәрлек берлекләре һәм ассоциацияләре, башка коммерцияле булмаган оешмалар вәкилләре;

2) Урта Тигәнәле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары вәкилләре;

3) кече һәм урта бизнес вәкилләре;

4) инфраструктура оешмалары вәкилләре.

## IV. СОВЕТНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

8. Үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен Совет хокулы:

1) федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнарыннан һәм Урта Тигәнәле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарыннан һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мәнфәгатьләрен белдерүче коммерцияле булмаган оешмалардан карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматны законнарда билгеләнгән тәртиптә сорарга һәм алырга;

2) Совет утырышларында карау өчен төрле мәсьәләләрне әзерләү буенча Совет әгъзаларына йөкләмәләр бирү;

3) карала торган мәсьәләләрне хәл итү өчен Совет утырышларына Федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнары, Урта Тигәнәле авыл

җирлеге җирле үзидарә органнары вәкилләрен, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары җитәкчеләрен һәм Урта Тигәнәле авыл җирлегенең башка оешмалары җитәкчеләрен, утырышның көн тәртибендәге мәсьәләләрне караганда аларның булуы максатка ярашлы булган бәйсез экспертларны чакырырга;

4) Совет компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча эшче төркемнәр булдыру.

9. Совет үз эшчәнлеген Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә алып барырга тиеш.

## V. СОВЕТ ЭШЕН ОЕШТЫРУ

10. Совет үз эшчәнлеген утырышлар формасында алып бара. Совет утырышы, әгәр анда Совет әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

11. Совет утырышлары кирәк булганда үткәрелә.

12. Совет карарлары утырышта катнашучы Совет әгъзаларының гади күпчелек тавышлары белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булган очракта, Совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Кайбер очракларда Совет карарлары сораштыру юлы белән кабул ителергә мөмкин.

13. Совет утырышы нәтиҗәләре буенча совет рәисе яки аның урынбасары тарафыннан имзалана торган утырыш беркетмәсе рәсмиләштерелә.

14. Совет утырышлары турында мәгълүмат Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» кушымтасында бастырыла.

15. Совет эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү, Совет утырышларын үткәрүгә әзерлек (Совет әгъзаларын чираттагы утырыш, Советның көн тәртибе турында мәгълүмат бирү, әгъзаларны тәэмин итү,

Советны кирәкле мәгълүмати материаллар һәм документлар белән, карарлар проектларын әзерләү, беркетмәләрне рәсмиләштерү) Урта Тигәнәле авыл җирлеге Советы секретаре башкара, ул Совет секретаре булып тора.